**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы, 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы, 2016 елның 9 июлендәге ПУ-588 номерлы, 2017 елның 7 июлендәге ПУ-608 номерлы, 2018 елның 19 маендагы ПУ-381 номерлы, 2018 елның 30 маендагы ПУ-397 номерлы, 2018 елның 26 июлендәге ПУ-541 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге ПУ-130 номерлы, 2019 елның 24 маендагы ПУ-294 номерлы, 2019 елның 24 июнендәге ПУ-361 номерлы, 2020 елның 23 маендагы ПУ-305 номерлы, 2020 елның 11 августындагы ПУ-473 номерлы, 2020 елның 30 ноябрендәге 788 номерлы һәм 2020 елның 28 декабрендәге ПУ-889 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Указда:

атамасында «ауның параметрларын» сүзләрен «ауга чикләүләр» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «23 статьяның 5 кисәге,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «ауның параметрларын» сүзләрен «ауга чикләүләр» сүзләренә алмаштырырга;

$1^1$ пунктта «ауның параметрларын» сүзләрен «ауга чикләүләр» сүзләренә алмаштырырга;

б) Указга кушымтаның атамасында «ауның параметрлары» сүзләрен «ауга чикләүләр» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 20 сентябрь
№ ПУ-731